| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКЛЮЧИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА РЕСПУБЛИКА<br>ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР КЛЮЧИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | с.Большие | **КАРАР** |
| **«02» июне 2023 ел** | Ключи | **№127** |

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлеге башлыгы урынбасары З. Р. Гатауллинның Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турындагы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, Зур Ключи авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән, Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1.1. физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның берсе дә мирас алудан баш тартса һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

1.2. салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

1.3. җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.Признать утратившим силу решение Совета города Зеленодольска от 05 декабря 2022 года №95 «О дополнительных основаниях признания безнадежными к взысканию недоимки по местным налогам, задолженности по пеням и штрафам».

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Зеленодольск муниципаль районы, Зур Ключи авылы, Волостнов урамы, 16а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Зур Ключи авылы, Волостнов урамы, 21 йорт (кибет бинасы) адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

**Башлык Урынбасары**
**Зур Ключи авыл җирлеге** **З.Р.Гатауллин**